**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

_______________　　　　ПР-175 19.09.2024　　　　№ ____

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы буенча
2024/2025 елгы җылыту сезонын башлау турында

Көзге-кышкы сезон башлануга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы «Җылыту сезонына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында»гы боерыгына таянып, мәктәп, мәктәпкәчә, медицина учреждениеләрендә нормаль шартлар тудыру һәм температура режимын саклау максатыннан, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җылылык белән тәэмин итүче оешма җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

1.1. Актаныш муниципаль районы территориясендә социаль, мәдәни һәм көнкүреш билгеләнешендәге объектлар өчен 2024-2025 елгы җылыту сезонын 2024 елның 23 сентябреннән башларга дип билгеләргә.

1.2. Диспетчерлык һәм авария хезмәтләренең ышанычлы һәм өзлексез эшләвен тәэмин итәргә, социаль өлкә объектларын җылылык белән тәэмин итүдә өзелү куркынычы янаган авария һәм авария алды очракларында кичекмәстән Актаныш районының Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә һәм Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә хәбәр итәргә.

2. Мәгариф, мәдәният бүлекләре җитәкчеләренә, Актаныш район үзәк хастаханәсе баш табибына, объектларның кышкы шартларда файдалануга әзерлеге турында документлар белән, җылылык җибәрүчеләргә заявка бирергә тәкъдим итәргә.

3. Предприятие, учреждение җитәкчеләренә үз объектларына җылылык җибәрү буенча тиешле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А.Ильясов